**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 27 нотябрь

№ 900

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник өлкәгә караган эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән яшьләр инновация иҗат үзәкләрен оештыру һәм (яисә) аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 ноябрь, 972 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник өлкәгә караган эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән яшьләр инновация иҗат үзәкләрен оештыру һәм (яисә) аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 ноябрь, 972 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 пунктта «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник өлкәгә караган эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән яшьләр инновация иҗат үзәкләрен оештыру һәм (яисә) аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен расларга (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\900.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 8 ноябрь, 972 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 27 ноябрь, 900 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен билгели.

1.2. Әлеге Тәртиптә кулланылучы төп төшенчәләр:

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

эшмәкәрлек субъекты – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә танылган кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты;

Иҗат үзәге – үз эченә турыдан-туры санлы җитештерү технологиясен файдалану өчен билгеләнгән һәм заманча технологияләр нигезендә тиз прототиплаштыруны, тәҗрибә үрнәкләрен, бер данәле һәм күп серияле продукция эшләргә мөмкинлек биргән җайланманы, шулай ук моның өчен кирәкле урыннар һәм инфраструктураны алган, балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән мөлкәт комплексы;

Конкурс комиссиясе – Иҗат үзәкләрен төзү һәм үстерү буенча эшмәкәрлек субъектлары проектларын конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү өчен Вәкаләтле орган тарафыннан оештырылган комиссия (алга таба – тиешенчә конкурс сайлап алуы, проектлар).

1.3. Субсидияләр түбәндәге максатларда бирелә:

балалар һәм яшьләрнең инновацион идеяләрен тормышка ашыру, тикшерү һәм коммерцияләштерү өчен заманча турыдан-туры санлы җитештерү җиһазларыннан файдалана алуларын тәэмин итү;

балалар һәм яшьләрнең инновацион иҗатына булышлык күрсәтү, шул исәптән һөнәри тормышка ашыру һәм яшьләр эшмәкәрлегенең үзмәшгульлеген тәэмин итү максатларында;

продукция һәм технологиянең өстенлекле төрләрен эшләүне гамәлгә ашырган балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына техник һәм җитештерү ягыннан булышлык күрсәтү;

Россия Федерациясенең башка Иҗат үзәкләреннән файдаланучылар белән багланышлар, тәҗрибә уртаклашу;

Иҗат үзәге базасында үткәрелә торган конференцияләр, семинарлар, эш очрашуларын оештыру;

Иҗат үзәкләреннән файдаланучыларның мәгълүматлар базасын будыру;

Иҗат үзәкләреннән файдаланучылар җиһазларның мөмкинлекләрен үзләштерү максатларында даими өйрәтүче чаралар үткәрү һәм өйрәтүче программаларны гамәлгә ашыру.

1.4. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары, шулай ук Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган акча кысаларында бирелә. Субсидия бирү шарты булып эшмәкәрлек субъекты тарафыннан Иҗат үзәген төзү тора.

1.5. Субсидия түбәндәгеләргә бирелә:

югары технологик җиһазлар (запас өлешләр һәм чыгым материаллар комплекты белән), электрон-санау техникасы (мәгълүмат эшкәртү өчен җиһазлар), программалар белән тәэмин итү, видеоконференцияләр үткәрү өчен җиһазлар, периферия җайланмалары, күчерү-күбәйтү җиһазлары сатып алу, шулай ук элемтәне тәэмин итү;

Иҗат үзәге гамәлгә ашыра торган инновацион эшчәнлеккә балаларны һәм яшьләрне җәлеп итү буенча мәгариф проектларын һәм чараларын финанс белән тәэмин итү.

Эшмәкәрлекнең бер субъектына субсидиянең максималь күләме 7 млн. сумнан артып китә алмый, шул исәптән 1 млн. сумнан артык булмаганы – даими өйрәтүче чаралар үткәрүгә, Россия Федерациясендәге башка Иҗат үзәкләре кулланучылары белән багланышлар, тәҗрибә уртаклашуга, Иҗат үзәге базасында үткәрелә торган конференцияләр, семинарлар һәм эш очрашулары оештыруга тотыла.

## II. Гариза бирүчеләргә таләпләр

2.1. Эшмәкәрлек субъекты түбәндәге шартларны бер үк вакытта үтәгән очракта субсидия алуга дәгъва итәргә хокуклы:

2.1.1. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килү.

2.1.2. Эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә теркәү һәм алып бару.

2.1.3. Эшмәкәрлек субъектының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиеш салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча, шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминиятләү кертемнәре буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау.

2.1.4. Проектның тулы бәясенең 5 процентыннан ким булмаган күләмдә эшмәкәрлек субъектының проектны тормышка ашыруга юнәлдерелгән үз акчасы булу.

## III. Субсидия бирүгә документлар әзерләү

3.1. Конкурс сайлап алуында катнашу өчен эшмәкәрлек субъекты әлеге Тәртип таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән конкурс заявкасын тапшырырга тиеш.

3.2. Конкурс заявкасы кәгазьдә тапшырыла.

Конкурс заявкасы составындагы барлык документлар анык бастырылган һәм барлык пунктлар буенча да тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела). Бозулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, мөһер белән таныкланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле зат мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш.

Конкурс заявкасының барлык битләренә сан сугылган булырга тиеш. Документлар күчермәләре раслауга вәкаләтле зат имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) булырга тиеш. Конкурс заявкасы тегелгән һәм раслауга вәкаләтле зат имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда), конкурс заявкасының икенче ягында битләрнең гомуми саны күрсәтелгән булырга тиеш.

3.3. Конкурс заявкасы составында кирәкле документлар булмау, әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән конкурс заявкасын рәсмиләштерүгә таләпләрнең бозылуы, яисә эшмәкәр тарафыннан тапшырылган документларда әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган шартлар үтәлүне раслый торган белешмәләр булмау, шулай ук «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның

14 статьясындагы 5 өлештә каралган очраклар конкурс заявкасын конкурс сайлап алуына кертүдән баш тартуга нигез булып тора.

3.4. Конкурс заявкасын әзерләү буенча барлык чыгымнарны эшмәкәрлек субъекты тота.

3.5. Әлеге Тәртип һәм конкурс сайлап алуында катнашу өчен тутырылырга кирәкле документлар формалары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле орган сайтында урнаштырыла.

## IV. Конкурс заявкасы составында документлар исемлеге

4.1. Конкурс заявкасы түбәндәге документларын үз эченә ала:

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча, вәкаләтле зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) белән расланган субсидия бирүгә гаризаны;

Иҗат үзәген төзү һәм үстерү концепциясен;

Иҗат үзәге хезмәтләренә булуы ихтимал сорауны бәяләүне (булуы ихтимал клиентлар санын);

Иҗат үзәге белән идарә планын;

Иҗат үзәгенең гомумиләштерелгән планировкасын;

конкурс заявкасын тапшырган вакытка эшмәкәрлек субъекты шуңа охшаш ярдәм алганы булмавы турында хәбәрнамәне;

проектның финанс анализын;

эшмәкәрлек субъекты (агымдагы хисап чорында теркәлгәннәреннән тыш) тарафыннан расланган соңгы хисап датасына хуҗалык эшчәнлегенең хисап чорына бухгалтер (финанс) хисабын;

Иҗат үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле, әлеге Тәртипнең 4.2 пунктында каралган параметрларга туры килә торган җиһазлар составын;

проектны тормышка ашыру планын;

Иҗат үзәген финанслауга субсидияне тоту юнәлешен;

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча, вәкаләтле зат имзасы һәм эшмәкәрлек субъекты мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) белән расланган Иҗат үзәге эшчәнлегенең планлаштырылган нәтиҗәләре хакында мәгълүматны;

Иҗат үзәгендә җиһазлар урнаштыру өчен 120 кв.метрдан зур булмаган мәйданлы, үзенеке булган, арендага алынган яки бушлай файдалануга бирелгән биналары барлыгын раслый торган документлар күчермәләре;

кимендә өч гомуми белем бирүче оешма белән хезмәттәшлек турында шартнамәләр күчермәләре;

кимендә бер гомуми техник юнәлештә югары белем бирүче оешма белән хезмәттәшлек турында шартнамәләр күчермәләре;

эшмәкәрлек субъектлары белән Иҗат үзәге тарафыннан прототиплар һәм эшләнмәләр әзерләү буенча хезмәт күрсәтү турында шартнамәләр (кимендә өч шартнамә) күчермәләре;

билгеләнгән тәртиптә расланган Иҗат үзәген «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәренә тоташтыруны тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтә торган оешма белән шартнамә күчермәсен;

штатта Иҗат үзәге җиһазларының бөтен спектры белән эшли белгән кимендә ике белгеч барлыгын раслаган, билгеләнгән тәртиптә расланган дипломнар (сертификатлар, таныклыклар), хезмәт кенәгәләре һәм хезмәт шартнамәләре күчермәләрен;

штатта балалар белән эш буенча кимендә бер белгеч барлыгын раслаган, билгеләнгән тәртиптә расланган белем турында диплом, хезмәт кенәгәсе һәм хезмәт шартнамәсе күчермәләрен.

4.2. Иҗат үзәге эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиһазлар параметрлары:

прототипларны һәм эшләнмәләрне 3D-проектлау һәм әзерләү, фрезер, токарь, слесарь, эретеп ябыштыру, электромонтажлау эшләре үткәрү мөмкинлеге;

балалар һәм яшьләр белән эшләү өчен куркынычсызлык;

җиһазларның җыйнаклыгы һәм Иҗат үзәге бинасында урнаштыруның һәм файдалануның санитар-техник нормаларына туры килүе.

4.3. Эшмәкәрлек субъектының законнарда һәм әлеге Тәртип белән билгеләнгән шартларга туры килүе түбәндәге документлардагы мәгълүмат нигезендә билгеләнә:

эшмәкәрлек субъектын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

эшмәкәрлек субъектын салым исәбенә кую турында таныклык;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

конкурс заявкасын биргән айга кадәр айның бер датасына бирелгән һәм билгеләнгән тәртиптә расланган эшмәкәрлек субъектының Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиеш салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча үтәмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

конкурс заявкасын биргән айга кадәр айның бер датасына бирелгән һәм билгеләнгән тәртиптә расланган Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминиятләү кертемнәре буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган белешмә;

эшмәкәрлек субъекты (агымдагы хисап чорында теркәлгәннәреннән тыш) тарафыннан расланган соңгы хисап датасына хуҗалык эшчәнлегенең хисап чорына бухгалтер (финанс) хисабы;

Иҗат үзәге урнашкан күчемсез мөлкәт объектына (бинага) хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (эшмәкәрлек субъектының күчемсез мөлкәт объектына милек хокукы булганда), яисә бинага ия булу хокукын һәм (яки) бинадан файдалану хокукын раслый торган бүтән документ.

Вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны законнарда билгеләнгән тәртиптә ала. Эшмәкәрлек субъекты шулай ук Вәкаләтле органга әлеге документларның эшмәкәрлек субъекты мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу

йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле зат имзасы белән расланган күчермәсен тапшырырга хокуклы.

4.4. Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен эшмәкәрлек субъектлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тоталар.

## V. Конкурс заявкаларын кабул итү һәм карап тикшерү

5.1. Конкурс заявкаларын кабул итүне вәкаләтле орган тормышка ашыра.

Конкурс заявкаларын кабул итү чоры, конкурс комиссиясе утырышы датасы һәм вакыты Вәкаләтле орган карары белән билгеләнә.

Конкурс заявкаларын кабул итү чоры, конкурс комиссиясе утырышы датасы һәм вакыты турында мәгълүмат конкурс заявкаларын кабул итү башланганга кадәр эш көннәрендә исәпләнүче өч көн алдан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.2. Конкурс заявкасы кергән көнендә Вәкаләтле орган тарафыннан заякаларны теркәү журналында (алга таба – журнал) теркәлә. Конкурс сайлап алуында катнашырга бер конкурс заявкасы да бирелмәсә, конкурс сайлап алуы булмады дип танылa.

5.3. Конкурс заявкалары журналда теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртип таләпләренә туры килүгә тикшерелә.

5.4. Конкурс заявкасын конкурс сайлап алуында катнаштыруга рөхсәт бирү хакында яки конкурс сайлап алуында катнаштыруга рөхсәт бирмәү турында мәгълүмат конкурс комиссия утырышы үткәрелгән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.5. Конкурс сайлап алуын конкурс комиссиясе үткәрә. Конкурс комиссиясе составы Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

5.6. Конкурс сайлап алуы нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынулары булган затлар (шул исәптән конкурс заявкалары биргән яисә конкурс заявкалары биргән эшмәкәрлек субъекты штатында торган) яисә конкурс сайлап алуында катнашучылар йогынты ясый алган затлар (шул исәптән эшмәкәрлек субъекты катнашучылар (акционерлары), аларның идарә органнары әгъзалары, эшмәкәрлек субъектының кредиторлары булган физик затлар), шулай ук финанс тикшерүен гамәлгә ашырырга вәкаләтле затлар конкурс комиссиясе әгъзалары була алмый.

5.7. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы һәм вакыты турында мәгълүматны конкурс комиссия утырышы үткәреләсе көнгә кадәр соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштыра.

5.8. Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, конкурс комиссиясе утырышы хокуклы була.

5.9. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

5.10. Конкурс заявкалары конкурс комиссиясе утырышында юридик зат-гариза бирүче җитәкчесе яки шәхси эшмәкәр-гариза бирүче катнашында яисә законнарга таянып рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә аларның вәкиле катнашында карап тикшереләләр.

5.11. Проектларны конкурс сайлап алуының ачыклыгына «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында онлайн-трансляция үткәрү юлы белән ирешелә.

5.12. Конкурс заявкаларын карап тикшергәндә конкурс комиссиясе түбәндәге критерийләр белән эш итә:

проектны эшләү дәрәҗәсе;

проектның концепциясе;

проектның командасы.

Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс заявкаларын конкурс сайлап алуының һәр критерие буенча 5 баллы шкала нигезендә бәяли (1 дән 5 кә кадәр).

Конкурс комиссиясе тарафыннан кимендә 10 балл җыйган конкурс заявкалары сайлап алына.

Субсидияләр конкурс заявкалары иң күп санда балл җыйган гариза бирүчеләргә бирелә. Бу чакта конкурс сайлап алуы җиңүчеләре саны конкурс комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм (яки) федераль бюджет акчасы исәбеннән агымдагы елда Иҗат үзәкләрен төзү һәм үстерү буенча чараларны томышка ашыруга бюджет ассигнованиеләреннән бүлеп бирелгән лимитлардан чыгып билгеләнә.

5.13. Конкурс сайлап алуы нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурс сайлап алуы җиңүчеләрен билгеләү һәм аларга субсидияләр бирү турында;

субсидия бирүдән баш тартылган конкурс сайлап алуы катнашучыларын билгеләү турында.

5.14. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны конкурс комиссиясе секретаре алып бара. Беркетмәне конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көнне конкурс комиссиясе рәисе раслый.

5.15. Беркетмә расланган көненнән соң эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштыра.

5.16. Конкурс комиссиясе гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына гариза бирүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

5.17. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән биш көн эчендә Вәкаләтле орган конкурс сайлап алуы җиңүчесе белән субсидия бирү турында шартнамә төзи.

Субсидия бирү турында шартнамәдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия алучының үз акчасы исәбеннән проектны финанслашуны гамәлгә ашыру шартлары, субсидияне файдалану турында хисап бирү тәртибе, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидиянең хисап финанс

елында файдаланылмаган өлешен кире кайтару тәртибе, Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, әлеге Тәртип һәм шартнамә шартларын үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы карала.

5.18. Вәкаләтле орган субсидияне максатчан файдалану һәм субсидия бирү турында шартнамәдә күрсәтелгән максатчан күрсәткечләргә ирешү хакында мәгълүмат бирүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

5.19. Субсидияне файдалану турында хисаплылык формасы, хисаплылыкны тапшыру тәртибе һәм вакытлары субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнә.

5.20. Субсидияләр субсидия алучы тарафыннан проектны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслашу буенча үз акчасы исәбеннән чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документларны тапшырганнан соң, Вәкаләтле орган тарафыннан акчаны субсидия алучының исәп-хисап счетына күчерү юлы белән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә бирелә.

5.21. Бирелгән субсидияләр Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет керемено түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидияне максатчан файдалану турында хисапны тапшырмау яисә үз вакытында тапшырмау;

субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартларны бозу очраклары билгеле булу;

субсидияне максатчан файдаланмау;

календарь елы нәтиҗәләре буенча проектны тормышка ашыруның шартнамәдә каралган нәтиҗәләренә ирешмәү;

Вәкаләтле органга конкурс заявкасында күрсәтелгән дөрес булмаган белешмәләр бирү.

Субсидия алучы тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше булган очракта алар хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә субсидия алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатын һәм тәртибен саклауны тикшерүне гамәлгә ашыралар.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозганда Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән вакытлар узган көннән соң календарь көннәрдә исәпләнгән 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча чаралар күрә.

5.22. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерүдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

___